**Татар матбугаты системасында яңа тип басмалар**

*Р.Л.Зәйни, КФУ доценты,*
*филология фәннәре кандидаты*

Совет чорыннан соң Россия матбугаты элеккеге традицияләрнең иң уңайларын саклап иҗат итсә дә, бик күп үзгәрешләргә дә дучар булды. Иң беренче чиратта шәхси матбугат барлыкка килүне күрсәтергә кирәк. Икенчедән, күтәрелгән темалар һәм проблемаларның, XX гасырның 90 нчы елларына кадәр булганнары белән чагыштырганда, җир белән күк арасы булуын күреп тә, укып та беләбез. Яңалыклар моңарчы кулланылмаган жанрлар формалашуда да чагыла, монысы - өченчедән. Матбугатның базар икътисады шартларында товарга әйләнүе, шул сәбәпле тираж арттыру өчен журналистларның уңай гына түгел, тискәре, регрессив, җәмгыятьне артка тартучы темаларны күтәреп чыгуына да көн саен шаһит булып торабыз. Бу яңалыклар нигездә чит ил журналистикасыннан безнең татар матбугаты битләренә дә бәреп керде.

Үзгәрешләр арасында таблоидлашу күренешен дә аерып күрсәтергә мөмкин. *Таблоид* ул – А3 форматындагы басма. Әмма төп сыйфаты аның белән генә төгәлләнми. Инглизчәдән кергән «инфотейнмент» төшенчәсе (information – мәгълүмат, entertainment – күңел ачу) таблоидлашу процессының нигезендә ята, андый басмалар, билгеле булганча, аналитикага урын бирүне уйлап та карамый. Материаллары кыска, укучыны уйланырга этәрми, күбрәк басым зур һәм искитәрлек фотоларга ясала. Анда да фотоларның аеруча куркыныч, ямьсез күренешләрне сурәтләгәне, ягъни укуычыга тээсир көче зур булганы сайланыла. Газета битләрендә атаклы кешеләрнең эшчәнлеге һәм шәхси тормышы турындагы ярымъялган-ярымчын мәгълүматлар, шаккаттыргыч хәлләр, куркыныч җинаятьләр, гайре табигый күренешләр турында сөйләнелә.

Болар ярдәмендә кешеләрнең яшерен тойгылары канәгатьләндерелә. Шуңа күрә дә халык ул газеталарны егылып укый, тиражларын арттыра. Тиражы зур булгач, реклама бирүчеләр өчен дә ул кирәкле басмага әверелә. Шуннан чыгып, күп кенә басмалар реклама ярдәмендә матди хәлне яхшыртыр өчен бу заманда таблоидка әйләнергә кирәк, дигән нәтиҗәгә килә. Дөресен әйткәндә, таблоидлашу ул редакция өчен ике яклы файда (әмма аудитория өчен түгел): рекламадан да керем килә, шул ук вакытта «сары» материалларны әзерләүгә күп вакыт, тырышлык һәм югары осталык дәрәҗәсе дә таләп ителми. Ә бит җәмгыятьтәге сәяси, икътисади, социаль проблемаларны күтәрүгә һәм чишүгә юнәлдерелгән мәкаләләр, журналист тикшерүләре, күзәтүләр язу күпкә зуррак чыгымнар сорар иде.

Кызганыч, бүгенге көндә инде шактый гына сыйфатлы дип саналган газета-журналлар стиленә дә инфотеймент кереп бара. Моны реклама бирүчеләр түгел, укучылар, журналистлар, редакторлар үзләре таләп итә, шулай дөрес дип таба: җитди мәгълүматны да, еш кына, кабул итү уңайлырак булсын дип, җиңеләйтә, кәеф күтәрүгә кайтарып калдыра. Шул рәвешчә, алар

да таблоидлаша (инглизләр шулай ди) яки бульварлаша (монысы алманнар термины). Таблоидлашу – басманың сыйфатын төшерү, тема төрлелеген югалту, текстка караганда, торган саен күбрәк һәм зуррак фотолар бастыру.

Татар матбугатында таблоид стиленә барысыннан да ныграк туры килүче «Кәеф ничек?» басмасы бар иде. Аның язмаларына кереп китмичә, беренче битендәге анонсларга күз салу да газетаның юнәлешен аңларга ярдәм итә. «КН хәбәрчесе: Сәнифә Рангулова дурацкий куртка сатып алды» (К.н.?, 2012, 7-13 ноябрь), «Фәнис Җиһанша Илсур Метшиннан да матуррак» (К.н.?. 2012, 19-25 дек.), «Ривкат абыйның бармакларын чабып өзгәннәр» (К.н.?, 2012, 8-14 авг.) – газетада менә шундый башисемнәр һәм шуларга туры килерлек зур-зур фотолар урын алган.

Матбугат дөньясында таблоидлашуга капма-каршы бара торган процесс та күзәтелә: таблоидлар сыйфатларын яхшырта, тирән эчтәлекле язмаларга өстенлек бирә башлый. Шул рәвешчә, таблоидлар квалоидларга әверелә. *Квалоид* – инглиз сүзе, quails һәм tabloid дигәннәреннән кушып ясалган, сыйфатлы таблоид дигәнне аңлата.

Безнең татар матбугатында чыгып килүче басмаларның шактые, таблоид булудан бигрәк, әнә шул квалоид дигән төргә туры килми микән әле. Квалоидларда Татарстандагы икътисадый хәл турындагы аналитика белән тузга язмаган мәзәкләр яки теге дөньяны сурәтләгән язмалар бер-берсенә комачау итмичә яши бит.

Мисал өчен, «Татарстан яшьләре» битләрендә инде ничә еллар чыгып килүче «Абау!» сәхифәсен алыйк. Бер ирнең хатынын үтерергә ябышуы, аннан полиция килеп алып киткәч, машинада җан тәслим кылуы (Т.Я., 2014, 23 гыйнв.) яки Яшел Үзән районындагы бер картның күрше карчыгын яндырып үтерә язуы (Т.Я., 2013, 21 дек.) турындагы «җиңелчә» хәбәрләр газетаны квалоидларга якын итә. Яки «Укыдыгызмы-ишеттегезме?» рубрикасына тукталыйк. Африкадагы Свазиленд короленең 15нче тапкыр өйләнүе (Т.Я., 2014, 23 гыйнв.) яки Кытайның Дафен шәһәрендәге махсус «ферма»дан миллионнан артык таракан чыгып качуы (Т.Я., 2013, 29 авг.) турындагы хәбәрләр белән беррәттән, газетада Россиядә медицинаның торышын анализларга омтылган «Карыйсызмы-юкмы, кайтып китәм бит!» (авторы Назилә Сафиуллина; Т.Я., 2013, 21 сент.) яки Айдар Хәлимнең милләт язмышы өчен борчылып язылган «Бүген әйтелергә тиешле сүз» мәкаләләре (Т.Я., 2012, 18 сент.) уңышлы гына «күршелек» итә.

Танылган публицист В.Мамонтов квалоид турында ачыктан-ачык «сыйфатлы эчлекне сары тышка төрү» дип билгеләде [8].

Квалоидлар аерым ММЧ төреме? Шул турыда фикерләрне фәнни әдәбиятта Е.Л.Вартанова [1; 2], А.А.Монастырская [3], А.В.Прытков [4; 5] В.Скоробогатько [6; 7], С.Л.Страшнов [8; 9] хезмәтләрендә табарга мөмкин. Алардагы мәгълүматларны һәм шәхси күзәтүләрне туплап, квалоидларга хас булган төп сыйфатларны күздән кичерик әле.

Беренчедән, алар тышкы яктан таблоидларга тартым. Бу рәсемнәрнең күплегендә, аларның зур форматта булуында, газета теленең халыкка якынлыгында, кайчакта әдәби телдән шактый читләшүендә чагыла. Газета

үзенчә оригиналь, новарторларча версткалана, әйтик, мәзәкләр традицион формада ахыргы биттә яки бит астында түгел, ә газетаның исеменнән дә өскә урнаштырылырга мөмкин.

Шул ук вакытта газета битләрендә социаль тормыш тирәннән өйрәнелә, мәгариф, сәламәтлек саклау, җәмгыять тормышына кагылышлы җитди язмалар басыла.

Гомумән, квалоидның күтәрмәгән-яктыртмаган темасы юк, ул махсуслашырга омтылмый, аның өчен барлык вакыйга да азык булып тора ала, газета дөньядагы бар нәрсә турында да яза алырлык басмага әверелә.

Квалоидлар өчен традицион жанр кысалары юк. Шуңа күрә дә без бүген халык аеруча күп укый торган зур тиражлы басмаларда чиста аналитик жанрдагы язмаларны авырдан табабыз. Чынбарлыкта, квалоидларга хас булганча, мондый басмаларда жанрлар арасындагы чикләр югала, алар бер-берсенә охшый бара.

Шулай ук редакциянең халык белән якыннан аралашырга омтылуы, төрле чаралар (түгәрәк өстәл, кайнар элемтә, очрашулар, лотерея, анкеталар) үткәрүе дә аны бер үк вакытта сыйфатлы матбугатка да, сыйфатсызына да якынайта. Чөнки ул очрашуларның максаты – күбрәк халыкка үзе турында игълан бирү, абунәчеләр санын арттыру, тиражны үстерү. Икенче яктан караганда, шулай аралашу халыкны борчыган проблемаларны яхшырак аңларга ярдәм итә.

***Кыскартулар***

К.Н.? – Кәеф ничек?

Т.Я. – Татарстан яшьләре

***Әдәбият***

1. Вартанова Е.Л. Северная модель в конце столетия. СМИ стран Северной Европы между государственным и рыночным регулированием / Е.Л. Вартанова. – М., Изд-во Моск. Ун-та, 1997. – 184 с.

2. Вартанова Е.Л. Медиаэкономика зарубежных стран / Е.Л. Вартанова. – М., 2005. – С. 144.

3. Монастырская А. А. Таблоидная пресса в России, 1990 - 2000 гг. : диссертация ... кандидата филологических наук : 10.01.10. – Санкт-Петербург, 2003. - 190 с.

4. Прытков А.В. Квалоид как тип СМИ / А.В.Прытков // ВЕСТНИК ВГУ. Серия: Филология. Журналистика. – 2012, №2. – С. 206-210.

5. Прытков А.В. Квалоиды и развлекательно-информационные издания / А.В.Прытков // Коммуникация в современном мире. Материалы Всероссийской научно-практической конференции «Проблемы массовой коммуникации» 11-12 мая 2012 г. / Под редакцией В.В. Тулупова. – Воронеж, Изд-во Воронежск. гос. ун-та, 2012. – С.62-63.

6. Скоробогатько В. Настоящий немецкий порядок / В. Скоробогатько // Журналистика и медиарынок. – 2010. – № 2. – С. 39.

7. Скоробогатько В. Владимир Скоробогатько: Смерть – избитая тема / В.Скоробогатько // Школа мультимедийной журналистики. URL: http://echoschool.ru/sovety-mediakonsultanta/vladimir-skorobogatko-smert-%E2%80%93-izbitaya-tema (дата обращения: 10.02.2014).
8. Страшнов С.Л. Квалоид / С.Л. Страшнов // Журналист. – 2010. – № 9. – С. 64-65.
9. Страшнов С.Л. Квалоид как актуальное медиапонятие // С.Л.Страшнов // Журналист. Социальные коммуникации. – 2011. – №1. –С.82-85.